ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НОРМИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
БАЛТАСИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
НОРМА
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«29» ноябрь 2024 ел № 46/1

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы "Норма авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенә кергән гражданнар һәм оешмаларның мөрәҗәгатьләренә анализ ясау Тәртибенә үзгәрешләр кертү турында**

Гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, 2023 елның 4 августындагы 480-ФЗ номерлы "Россия Федерациясе гражданнарының мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында"гы Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында"гы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Норма авыл җирлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Норма авыл җирлеге Советының 2015 елның 03 ноябрендәге 35 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы "Норма авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенә кергән гражданнар һәм оешмаларның мөрәҗәгатьләренә анализ ясау Тәртибенә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

- 1 бүлекнең 1.2 пунктында "электрон хәбәрләр формасында" сүзләреннән соң "электрон документ формасында, шул исәптән "Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы" федераль дәүләт мәгълүмат системасын кулланып," сүзләрен (алга таба - Бердәм портал)," сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (baltasi.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Норма авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе З.Н. Низамова